**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7504**
**17.09.2025**

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2024 елның 22 октябрендәге 6968 номерлы Карары белән расланган «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы халыкларының милләтара элемтәләрен һәм дуслыгын ныгыту һәм шәһәр халкының ялын оештыру максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсын оештыруны һәм Яр Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә 2025 елның 29 ноябрендә үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә программаның кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 25 000 (егерме биш мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 17 сентябрендәге
7504 номерлы карарына
1 нче кушымта

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен
«Милли курчак» шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәрендә милләтара дуслыкны ныгыту максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- балаларны Татарстан Республикасында яшәүче халыклар мәдәниятенә җәлеп итү;

- балаларда актив тормыш позициясе формалаштыру;

- талантлы балаларга аларның иҗади потенциалын тормышка ашыруда ярдәм итү, баланы иҗади үсеше өчен бүләкләү;

- җәмәгатьчелек аңында, мөһим тәрбия институты буларак, гаиләне үстерү, аңа ярдәм итү һәм саклауның мөһимлеген формалаштыру;

- буыннар бәйләнешен саклау.

3. Конкурсны оештыруны һәм үткәрүне составы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) гамәлгә ашыра.

4. Оештыру комитетының төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

1) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча эшчәнлекне координацияләү;

2) конкурсны үткәрү, аның барышы һәм конкурска йомгак ясау турында нигезләмәне массакүләм мәгълүмат чаралары аша яктырту.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

5. Конкурста үз милләтен тәкъдим итүче 7 яшьтән 12 яшькә кадәрге кызлар катнаша ала.

6. Конкурс ике турда үткәрелә:

- читтән торып (сайлап алу туры): – заявка-анкеталар кабул итү һәм катнашучыларның видеоматериалын карау;

- финал (конкурс финалистлары катнашында гала-концерт).

7. Сайлап алу турында катнашу өчен әлеге нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча оештыру комитетына анкета-заявка җибәрергә кирәк.

8. Анкета-заявкалар 2025 елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча kukolka2021@yandex.ru  электрон почтасына, яисә Яр Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе (Ш.Усманов урамы, 5 (32/24) йорты, 5 кабинет) адресы буенча кабул ителә.

9. Сайлап алу туры: милли киемдә туган телдәге визитка, гаилә яки ярдәм төркеме белән иҗади номер 2025 елның 11 ноябрендә Яр Чаллы шәһәренең «Чишмә»

халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә (Ш.Усманов урамы, 5 (32/24) йорты) узачак.

10. Сайлап алу туры нәтиҗәләре буенча оештыру комитеты финалистларны билгели, 2025 елның 14 ноябреннән дә соңга калмыйча аларга чакыру хатлары җибәрелә.

11. Конкурсның финалы 2025 елның 29 ноябрендә Яр Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә (Ш.Усманов урамы, 5 (32/24 йорты) узачак.

12. Финалны үткәрү тәртибе:

1) «Визитка — Сөйләм культурасы» — катнашучылар туган телләрендә, милли киемдә үзләрен тәкъдим итәләр (2 минуттан да артык түгел, шигъри, музыкаль форма, проза рөхсәт ителә);

2) ярдәм төркеме: гаиләсе, сыйныф укучылары, милли-мәдәни автономиядә катнашучылар һәм башкалар белән берлектә башкарылган иҗади номер.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

13. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

- милли колорит: туган телне белү, милли кием;
- сәхнә осталыгы;
- иҗади индивидуальлек.

14. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты тарафыннан 10 баллы система буенча бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә. Конкурсның йомгаклары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

15. Иң күп бал җыйган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре дип танылалар. Призлы урыннар түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:

- «Мисс Индивидуальлек»;
- «Мисс Илһам»;
- «Мисс Елмаю»;
- «Мисс Сөйкемлелек»;
- «Мисс Талант»;
- «Мисс Нәзакәтлелек»;
- «Мисс Соклану»;
- «Мисс Тамашачы мәхәббәте»;
- «Мисс Дуслык».

16. Сайлап алу туры йомгаклары буенча өстәмә номинацияләр кертелергә мөмкин.

17. Конкурста катнашучылар бүләкләр, чәчәк букетлары, рәхмәт хатлары һәм дипломнар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Кече яшьтәге мәктәп
балалары өчен «Милли
курчак» шәһәр конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
кушымта

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен
«Милли курчак» шәһәр конкурсында катнашучының
анкета – заявкасы

Дата «___» __________ 2025 ел Анкета номеры__________
(оештыру комитеты тутыра)

1. Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме
_______________________________________________________________________
_________________________________________________________________

2. Туган көне __________________________ Яше _____________ (тулы яше)

3. Катнашучы нинди милләт исеменнән чыгыш ясый
___________________________________________________________________________

4. Күңел түрендәге хыялы_____________________________________________________
_______________________________________________________________________

5. Әнисенең исеме, атасының исеме /элемтә өчен телефоны
_________________________________________________________________

6. Әтисенең исеме, атасының исеме /элемтә өчен телефоны
_______________________________________________________________________

7. Кураторның (катнашучының җитәкчесе) исеме, атасының исеме /элемтә өчен телефоны _______________________________________________________

8. Катнашучы ярдәм төркеме белән берлектә нинди концерт номеры башкарачак *(исеме, кем башкара)*
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________